**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге составына керүче  Алших  торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре**

18  март 2024 ел                                                                 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге Алших авылы гражданнары җыенының 2023 елның 16 ноябрендәге  1 нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында»  дигән сорау буенча

«Сез Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге Алших авылы гражданнары җыенының 2023елның 16 ноябрендәге   1 нче номерлы карарының 2 пунктына аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертүгә ризамы» соравы буенча аны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

2. Алынган акчаларны түбәндәге эш төрләрен башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,  карап тоту;

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион  җирләү урыннарын төзекләндерү;

-торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә,  халык җыенында катнашучылар исемлегенә  492 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны-295 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 295  кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге составына керүче Алших авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2.  «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге Алших авылы гражданнары җыенының 2023 елның 16 ноябрендәге  1 нче номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертү турында»  дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлеге Алших авылы гражданнары җыенының  2023 елның 16 ноябрендәге  1 номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау,  карап тоту;

- коймалар төзү, төзекләндерү, традицион  җирләү урыннарын төзекләндерү;

-торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).».

4 Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Алших авылында махсус

җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Алших авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ___________ А.П. Андреев

Алших авыл җирлеге
башлыгы ___________________ А.П. Андреев